# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
## Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Сасмак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

30 ноябрь 2022 ел № 2

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 26 ноябрендә 13 сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, "2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган яшәүчедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризалыгыгыз бармы" мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Сасмак торак пунктында теркәлгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган акчаларны хәл итү өчен түбәндәге эшләргә юнәлдерелде:

а) Мүлмә авылында БВС сугышчыларына һәйкәл территориясен төзекләндерү

б) Сасмак авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм реконструкцияләү (су башнясын, тышкы суүткәргеч насос станциясен алыштыру)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 168 (йөз алтмыш сигез) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 90 (туксан) кеше, бу 54%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 90 (туксан) катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Сосмак торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2023 елда үзара салым акчасын, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Сасмак торак пунктында даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум (бер мең) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) Мүлмә авылында БВС сугышчыларына һәйкәл территориясен төзекләндерү;

б) Сасмак авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм реконструкцияләү (су башнясын, тышкы суүткәргеч насос станциясен алыштыру)

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.Р. Зиннәтуллин